МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ ____16/о______

П Р И К А З　　　　　　　　　　　　　　　　Б О Е Р Ы К

«__16___»_____01_________2025_

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-32 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү турында» 2024 елның 19 апрелендәге 98/о номерлы боерыгы, Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе утырышының 2024 елның 16 декабрендәге 17 номерлы беркетмәсе нигезендә, 2024 елның 8 ноябреннән 2024 елның 20 ноябренә кадәр уздырылган гавами фикер алышуларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кушымтада бирелә торган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.

2. Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсенең көньяк-көнбатыш районнарны үстерү бүлегенә (А.С.Харитоновка) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрүне;

әлеге боерыкны үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны;

«Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен файдаланыла торган координаталар системасында әлеге чикләрнең координаталары исемлеге булган территориаль зоналар чикләре турындагы белешмәләрне әлеге боерык үз көченә кергән көннән алып биш эш көне эчендә электрон рәвештә җибәрүне;

әлеге боерыкны ул басылып чыккан көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча Территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыруны.

3. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А.Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары В.Н.Кудряшев

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 2025 елның
16 гыйнварындагы 16/о
номерлы боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре**

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының
«Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең

# ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

I өлеш

## ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕН КУЛЛАНУ ҺӘМ КҮРСӘТЕЛГӘН КАГЫЙДӘЛӘРГӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТӘРТИБЕ

2025

**Эчтәлек**

1 нче бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Куллану өлкәсе

2 статья. Төп төшенчәләр

2 нче бүлек. Вәкаләтле органнар тарафыннан җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу турында нигезләмә

3 статья. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләре

4 статья. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү

3 нче бүлек. Физик һәм юридик затлар тарафыннан җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртү турында нигезләмә

5 статья. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртү

6 статья. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт

7 статья. Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт

8 статья. Шәһәр төзелеше регламентына туры килми торган җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану

4 нче бүлек. Вәкаләтле органнар тарафыннан территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында нигезләмә

9 статья. Территорияне планлаштыру документларын әзерләүгә гомуми таләпләр

5 нче бүлек. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча гавами тыңлаулар уздыру турында нигезләмә

10 статья. Гавами тыңлаулар турында гомуми нигезләмәләр

6 нчы бүлек. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында нигезләмә

11 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында гомуми нигезләмәләр

7 нче бүлек. Җирдән файдалануның һәм төзелешнең башка мәсьәләләрен җайга салу турында нигезләмә

12 статья. Территорияне комплекслы үстерү

## 1 нче бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Куллану өлкәсе

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) – техник регламентлар таләпләрен, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлегенең генераль планындагы территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәне (алга таба – генераль план), кызыксынган затларның кагыйдәләре һәм тәкъдимнәре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ Шәһәр кодексы), Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында, җир мөнәсәбәтләре, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка законнары һәм норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы, техник регламентлар таләпләрен исәпкә алып, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый һәм шәһәр төзелеше үсешенең төп юнәлешләрен билгели торган хокукый актлар нигезендә кабул ителгән шәһәр төзелешен зоналаштыру документы булып тора.

2. Кагыйдәләр капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү максатларында җир кишәрлекләреннән файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар белән җайга салына торган мәсьәләләр өлешендә җайга сала.

3. Кагыйдәләр белән җайга салына торган мөнәсәбәтләрнең субъектлары (катнашучылары) булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль берәмлек һәм аларның берләшмәләре халкы, физик һәм юридик затлар;

2) Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе;

3) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары, «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары;

4) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык);

5) республиканың башка башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары.

4. Кагыйдәләр Кагыйдәләр белән җайга салына торган мөнәсәбәтләрнең барлык субъектлары (катнашучылары) тарафыннан үтәлү өчен мәҗбүри.

5. Кагыйдәләр түбәндәгеләргә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салмый:

1) җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына хокуклар барлыкка килү, үзгәрү һәм туктатылу;

2) территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау;

3) федераль башкарма хакимият органнары карары буенча территорияне планлаштыру документациясен әзерләү һәм мондый документацияне раслау;

4) җир кишәрлекләрендә һәм капиталь төзелеш объектларында икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыру;

5) территорияне төзекләндерү;

6) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау.

6. Кагыйдәләр үз көченә кергәннән соң барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә карата кулланыла. Кагыйдәләр үз көченә кергәнче барлыкка килгән мөнәсәбәтләрдә Кагыйдәләр Кагыйдәләр үз көченә кергәннән соң барлыкка килгән хокукларга һәм бурычларга карата кулланыла.

7. Кагыйдәләр кешеләрнең гомере һәм сәламәтлеге иминлеген, капиталь төзелеш, мөлкәтне саклау, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларының ышанычлылыгын һәм иминлеген тәэмин итү максатларында законнар нигезендә кабул ителгән техник регламентлар, шулай ук җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу мәсьәләләре буенча башка норматив хокукый актлар белән беррәттән кулланыла.

8. Кагыйдәләр республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга, шулай ук Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында да урнаштырылырга тиеш.

2 статья. Төп төшенчәләр

1. Әлеге кагыйдәләр максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның биеклеге – капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзү, реконструкцияләү параметры, ул метрларда санлы кыйммәт рәвешендә билгеләнә, вертикаль буенча төзелеш мәйданы астындагы җирнең иң түбән планлаштыру билгесеннән бинаның, төзелмәнең, корылманың иң югары конструктив элементының (түбә парапеты, кәрниз, түбә очы, фронтонның өске өлеше, гөмбәз, шпиль, манара; бинаның, корылманың өске конструктив элементлары түбәгә чыгу һәм техник җиһазлар урнаштыру өчен өстәмә корылмалар, лифт шахталары булырга мөмкин) өске билгесенә кадәр үлчәнә торган ара буларак билгеләнә, бу вакытта түбәдәге антенналар, яшен үткәргечләр, вентиляция җиһазлары һәм башка электротехник һәм инженерлык җайланмалары бинаның, төзелмәләрнең, корылмаларның биеклеген билгеләгәндә исәпкә алынмый;

капиталь төзелеш объектының хәвефлелек классы – капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзү, реконструкцияләү параметры, Россия Федерациясе дәүләт баш санитария табибының «Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка объектларның санитар саклык зоналары һәм санитар классификациясе» СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 санитар-эпидемиологик кагыйдәләре һәм нормативларының яңа редакциясен гамәлгә кертү турында» 2007 елның 25

сентябрендәге 74 номерлы карарында каралган сәнәгать объектларының һәм производстволарының санитария классификациясе нигезендә куәтенә, эксплуатация шартларына, әйләнә-тирә мохиткә бүленеп чыга торган пычраткыч матдәләрнең характерына һәм санына, барлыкка килә торган тавыш, вибрациягә һәм башка зарарлы физик факторларга бәйле рәвештә кешенең яшәү тирәлегенә һәм сәламәтлегенә йогынты ясау чыганагы булган сәнәгать объектлары һәм производстволары, корылмалары классы буларак Рим исәпләү системасында санлы кыйммәт рәвешендә билгеләнә;

катлар саны – капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән параметры, ул катларда сан әһәмияте рәвешендә, техник катларны исәпкә алмаганда, мансарда катын да кертеп, җир өстендәге катлар саны буларак билгеләнә;

болдыр – капиталь төзелеш объектына керүне тәэмин итә торган лапас астындагы мәйданчык, пандус һәм баскыч булган төзекләндерү элементы;

мансарда каты (мансарда) – фасады тулысынча яисә өлешчә авыш, сынык яки кәкре түбә өслегеннән (өслекләреннән) ясалган кат, шул ук вакытта түбә яссылыгы һәм фасад кисешү сызыгы мансарда каты идәненнән иң күбе 1,5 м биеклектә генә була ала;

җир өсте каты – идән тамгасы җирнең иң түбән планлаштыру тамгасыннан түбән булмаган кат;

капиталь төзелеш объектларының җир кишәрлекләре чикләреннән чигенүе – капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзү, реконструкцияләү параметры, ул метрларда сан әһәмияте рәвешендә билгеләнә, ул җир кишәрлеге чиге белән капиталь төзелеш объектының тышкы дивары арасында җир кишәрлеге чиге белән капиталь төзелеш объектының тышкы дивары, шулай ук җирләрнең планлаштырылган тамгасы дәрәҗәсендә башка конструктив элементлар (шул исәптән җир өсте элементлары, җир кишәрлеге өслеге астындагы болдырларыннан, чокырчыклардан һәм капиталь төзелеш объектлары өлешләреннән тыш), җир кишәрлеге өслеге астындагы) яисә аларның җир өстенә проекцияләре арасындагы ераклык буларак билгеләнә торган ара;

җир кишәрлегенең алгы чиге – җир кишәрлегенең чиктәш яисә күпчелек өлеше урамнарга, юлларга, квартал эчендәге җәяүле юлларына, машина юлларына һәм гомуми файдаланудагы территорияләргә чыга торган чиге. Җир кишәрлегенең берничә алгы чиге булырга мөмкин. Хәзерге төзелеш эчендә урнашкан җир кишәрлегенең алгы чикләре булмаска да мөмкин. Җир кишәрлегенең алгы чикләре булмаган чикләре бүтән була;

төзелеш мәйданы – бинаның, төзелешнең, корылманың тышкы контуры буенча горизонталь кисемтә мәйданы, чыгып торган конструктив элементларны да кертеп, җирнең планировка тамгасы дәрәҗәсендә (баскычлардан һәм чокырчыклардан тыш);

капиталь төзелеш объекты мәйданы – капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзү, реконструкцияләү параметры, ул квадрат метрларда санлы әһәмият рәвешендә биналарның барлык җир өсте катларының мәйданнары суммасы буларак билгеләнә, техник, мансарда, шулай ук цоколь, подвал катларын да кертеп, антресольләр, галереялар, тамаша балконнары һәм башка мәйданнарны үз эченә ала, аларга заллар, верандалар, җәйге бүлмәләрнең балконнары, тышкы пыялалы галереялар, шулай ук башка биналарга күчүләр дә керә;

подвал каты – идән билгесе җир дәрәҗәсенең иң түбән планлаштыру билгесеннән аның биеклегенең яртысыннан күбрәгенә түбәнрәк булган кат;

җир кишәрлекләренең иң чик үлчәмнәре – җир кишәрлекләренең квадрат метрларда санлы кыйммәтләр рәвешендә билгеләнә торган максималь һәм минималь мәйданы, җир кишәрлекләренең алгы чигенең метрлардагы санлы күрсәткечләр рәвешендә билгеләнә торган минималь киңлеге һәм җир кишәрлекләрен характерлый торган һәм шәһәр төзелеше регламентлары нигезендә билгеләнә торган башка күләмнәр;

чокырчык – капиталь төзелеш объектының стенасына терәлеп торган, тәрәзә һәм/яисә ишек уемы булган җирдә тирәнлек рәвешендәге төзекләндерү элементы;

җир кишәрлеге чикләрендә төзелеш проценты – капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзү һәм реконструкцияләүнең җир кишәрлегенең суммар мәйданының нисбәте буларак билгеләнә торган процентларда санлы

кыйммәт рәвешендә билгеләнә торган параметры, ул яссы корылмалар, болдырлар, чокырчыклар, стилобатлар белән мәйданнарны һәм җир кишәрлеге астында урнашкан капиталь төзелеш объектлары өлешләрен исәпкә алмыйча, җир кишәрлегенең бөтен мәйданына карата төзелергә мөмкин;

гомуми файдалану территорияләре – парклар, скверлар, бульварлар, мәйданнар һәм башка төзекләндерелгән рекреацион территорияләр;

техник кат – инженерлык җиһазларын урнаштыру һәм коммуникацияләр салу өчен кат;

цоколь кат – бүлмәләрнең идән тамгасы җирнең иң түбән планировка тамгасыннан түбәнрәк булган кат.

Территорияне, кызыл линияләрне төзекләндерү, капиталь төзелеш объектын, капиталь төзелеш объектын капиталь ремонтлау төшенчәләре РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә кулланыла.

## 2 нче бүлек. Вәкаләтле органнар тарафыннан җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу турында нигезләмә

3 статья. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләре

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарәсе вәкиллекле органы – Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы советы вәкаләтләре:

1.1. проектлар буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибен, гавами тыңлауларны үткәрү срокларын, рәсми сайтны һәм (яисә) мәгълүмат системаларын, гавами тыңлаулар башлану турында хәбәрләр урнаштырыла торган мәгълүмат стендларына таләпләрне, гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү рәвешләрен, гавами тыңлауларны әзерләү тәртибен һәм беркетмә рәвешләрен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү тәртибен һәм рәвешләрен, гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен үткәрү тәртибен, гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләргә консультация бирү тәртибен раслау.

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башлыгы – Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башлыгы вәкаләтләре:

2.1 җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында карар кабул итү.

4 статья. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү

1. «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында күрсәтелгән җирле үзидарә органнары вәкаләтләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан

Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 3 нче бүлек. Физик һәм юридик затлар тарафыннан җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртү турында нигезләмә

5 статья. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртү

1. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы нигезендә билгеләнә.

2. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану түбәндәге төрләрдә булырга мөмкин:

1) рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре;

2) шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрләре;

3) рөхсәт ителгән файдалануның рөхсәт ителгән төп төрләренә һәм шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрләренә карата өстәмә буларак кына рөхсәт ителә торган һәм алар белән бергә гамәлгә ашырыла торган ярдәмче төрләре.

3. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның икенче төренә үзгәртү, техник регламентлар таләпләре үтәлгән очракта, шәһәр төзелеше регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның төп һәм ярдәмче төрләре, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән, дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән тыш, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан хокук ияләре тарафыннан өстәмә рөхсәтсез һәм килештерүсез мөстәкыйль сайлана.

5. Шәһәр төзелеше регламентлары гамәлдә булмаган яисә шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнмәгән җирләрдә урнашкан җир кишәрлекләреннән һәм

капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен үзгәртү турындагы карарлар федераль законнар нигезендә кабул ителә.

6. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану төрен үзгәртү җирләрнең максатчан билгеләнешен һәм категориясен үтәгәндә гамәлгә ашырыла.

7. Шәһәр төзелеше регламенты нигезендә җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану төрен үзгәртү хокукка ия булучылар тарафыннан рөхсәт ителми:

1) мондый кишәрлектә капиталь төзелеш объектын төзүгә бәйле рөхсәт ителгән файдалану төрләренә төзелешкә бәйле булмаган максатлар өчен бирелгән җир кишәрлегенә карата;

2) мондый җир кишәрлегендә файдалануның төп яисә шартлы рөхсәт ителгән төре булган капиталь төзелеш объекты булмаганда рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төренә карата;

3) шәһәр төзелеше регламентының гамәлдә булуы кагылмый торган җир кишәрлегенә карата;

4) шәһәр төзелеше регламенты билгеләнмәгән җир кишәрлегенә карата.

8. Җир кишәрлекләреннән файдалануның төп яисә шартлы рөхсәт ителгән төре мондый җир кишәрлегенә карата рөхсәт ителгән файдалануның тиешле төре турында белешмәләр Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына (алга таба – КМБДР) кертелгән көннән сайланган дип санала. КМБДР җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре турында белешмәләр кертү таләп ителми.

9. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер үк төрләре ярдәмче һәм шартлы рөхсәт ителгән файдалану төрләре исемлегендә бер үк вакытта булырга мөмкин. Мондый очракларда рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төре территориаль зонаның шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалануның төп төре белән бергә файдаланылса билгеләнә. Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төре төп буларак билгеләнү планлаштырылган очракларда кулланыла (РФ Шәһәр

төзелеше кодексының 39 статьясында каралган тәртиптә файдалануның мондый төренә рөхсәт алу шарты белән).

6 статья. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт

1. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт тиешле дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибендә бирелә. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты белән билгеләнә.

7 статья. Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт

1. Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт тиешле дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибендә бирелә. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты белән билгеләнә.

8 статья. Шәһәр төзелеше регламентына туры килми торган җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану

1. Әлеге кагыйдәләр гамәлгә кертелгәнче билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм шәһәр төзелеше регламенты билгеләнгән территорияләрдә урнашкан һәм билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентының гамәлдә булуы кагыла торган шәһәр төзелеше регламентына туры килми торган җир кишәрлекләреннән, капиталь төзелеш объектларыннан түбәндәге очракларда файдалану:

1) җир кишәрлекләреннән фактта файдалануның гамәлгә ашырыла торган төрләре тиешле территориаль зонаның шәһәр төзелеше регламентында күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләренә туры килмәсә;

2) җир кишәрлекләреннән файдалануның фактта гамәлгә ашырыла торган төрләре тиешле территориаль зонаның шәһәр төзелеше регламентында күрсәтелгән

җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләренә туры килеп, әмма бу вакытта әлеге җир кишәрлекләре территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зона чикләрендә урнашкан икән, аның чикләрендә җир кишәрлекләреннән файдалануның әлеге төрләре рөхсәт ителмәгән очракта;

3) капиталь төзелеш объектларыннан фактта файдалануның гамәлгә ашырыла торган төрләре тиешле территориаль зонаның шәһәр төзелеше регламентында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләренә туры килеп, әмма бу вакытта капиталь төзелеш объектлары истәлекле урын территориясендә, күрсәтелгән төрләрнең капиталь төзелеш объектларын урнаштыру рөхсәт ителми торган территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зона чикләрендә урнашкан булса;

4) капиталь төзелеш объектларының факттагы параметрлары тиешле территориаль зонаның шәһәр төзелеше регламентында капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларына туры килмәгән очракта;

5) капиталь төзелеш объектларының факттагы параметрлары тиешле территориаль зонаның шәһәр төзелеше регламентында капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларына туры килеп, ләкин бу вакытта әлеге капиталь төзелеш объектлары күрсәтелгән параметрлары булган капиталь төзелеш объектларын урнаштыру рөхсәт ителмәгән территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зона чикләрендә урнашкан булса.

2. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре шәһәр төзелеше регламентына туры килмәү түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

1) дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге яисә милеге чикләнмәгән, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән капиталь төзелеш объектлары биләгән җирләрдән, әгәр барлыкка килгән җирдән файдалану (җирлектә билгеләнгән факттагы чикләр) аркасында җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәрен үтәү мөмкин булмаса, законнарда билгеләнгән тәртиптә кагыйдәләр расланганчы, җир кишәрлекләрен булдыру, җир кишәрлекләрен бүлеп бирү ;

2) хосусый милектәге җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге яисә милек чикләнмәгән җирләрне (җир кишәрлекләрен) яңадан бүлгәндә башлангыч җир кишәрлегенең мәйданы 10 проценттан артмаган очракта җир кишәрлекләре барлыкка китерү;

3) җир кишәрлекләрен бүлгәндә, әгәр башлангыч җир кишәрлеге Кагыйдәләр кабул ителгәнче бирелгән булса, мондый җир кишәрлекләре өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы – 180 кв. метр кулланып, җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төренең коды 2.3 «блоклардан торак төзелеше» булган (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге п/0412 номерлы боерыгы нигезендә) җир кишәрлекләре төзү;

4) җир кишәрлегенең иң чик мәйданнан артып киткән өлеше мөстәкыйль җир кишәрлеге буларак формалаштырыла алмый икән һәм чиктәш җирләрдән файдаланучыларның ризалыгы булган очракта, шулай ук шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән җир кишәрлекләренең минималь мәйданы булган ике җир кишәрлеге төзү мөмкин булмаганда, шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән җир кишәрлекләренең максималь мәйданыннан артыграк җир кишәрлекләре барлыкка китерү;

5) җир кишәрлекләрен дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен алу максатларында бүлү һәм (яисә) яңадан бүлү.

## 4 нче бүлек. Вәкаләтле органнар тарафыннан территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында нигезләмә

9 статья. Территорияне планлаштыру документларын әзерләүгә гомуми таләпләр

1. Территорияне планлаштыру документларын әзерләүне Министрлык тәэмин итә.

2. Татарстан Республикасында территорияне планлаштыру проектларын формалаштыруга һәм әзерләүгә методик таләпләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 27 декабрендәге 3134-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган.

## 5 нче бүлек. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча гавами тыңлаулар уздыру турында нигезләмә

10 статья. Гавами тыңлаулар турында гомуми нигезләмәләр

1. Гавами тыңлаулар түбәндәге мәсьәләләр буенча яшәешнең уңайлы шартларына кеше хокукын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатларында үткәрелә:

1) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектларына, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында;

2) территорияне планлаштыру проектларына, территорияләрне планлаштыру проектларына үзгәрешләр кертүгә;

3) территорияне ызанлау проектларына, территорияне ызанлау проектларына үзгәрешләр кертүгә;

4) җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектларына;

5) капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карарлар проектларына.

2. Гавами тыңлаулар эш һәм ял көннәренә билгеләнергә мөмкин. Рәсми бәйрәм көннәрендә гавами тыңлаулар уздырылмый.

3. Эш көннәрендә гавами тыңлаулар башлану вакыты җирле вакыт белән 18 сәгатьтән иртәрәк билгеләнә алмый.

4. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре киңәш итү характерында була.

5. Проектлар буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе, гавами тыңлауларны оештыручы, гавами тыңлауларны уздыру срогы, рәсми сайт һәм (яисә) мәгълүмат системалары, гавами тыңлаулар башлану турында хәбәрләр урнаштырыла торган мәгълүмат стендларына таләпләр, гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү рәвеше, гавами тыңлауларны әзерләү тәртибе һәм беркетмә рәвеше, гавами тыңлауларны әзерләү тәртибе һәм нәтиҗәләре турында бәяләмә

формасы, гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен үткәрү тәртибе, шулай ук гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләргә консультация бирү тәртибе Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы һәм (яисә) җирле үзидарәнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

## 6 нчы бүлек. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында нигезләмә

11 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге кагыйдәләргә үзгәрешләр, әлеге статья үзенчәлекләрен исәпкә алып, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясында каралган тәртиптә кертелә.

2. Территориаль зоналар кагыйдәләрдә билгеләнмәгән торак пунктлар чикләреннән читтә урнашкан җир кишәрлекләрендә төзелеш ниятләре барлыкка килгән очракта, мондый җир кишәрлекләренең хокукый режимы тиешле территориаль зона билгеләү өлешендә Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү юлы белән билгеләнә.

## 7 нче бүлек. Җирдән файдаланының һәм төзелешнең башка мәсьәләләрен җайга салу турында нигезләмә

12 статья. Территорияне комплекслы үстерү

1. Территорияне комплекслы үстерү РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү проектларын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 елның 24 сентябрендәге 913 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының
«Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең

# ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

II өлеш

## ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕН ЗОНАЛАШТЫРУ КАРТАСЫ

2025

**Эчтәлек**

8 нче бүлек. Картографик материаллар исемлеге

13 статья. Картографик материалларның эчтәлеге

## 8 нче бүлек. Картографик материаллар исемлеге

13 статья. Картографик материалларның эчтәлеге

1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары:

1) Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар

2. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына кушымталар:

1) Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре картасы

**ПРАВИЛА ЗЕМЛЕПОЛЬЗОВАНИЯ И ЗАСТРОЙКИ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ САВРУШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

КАРТА ГРАДОСТРОИТЕЛЬНОГО ЗОНИРОВАНИЯ. ТЕРРИТОРИАЛЬНЫЕ ЗОНЫ



**ПРАВИЛА ЗЕМЛЕПОЛЬЗОВАНИЯ И ЗАСТРОЙКИ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ САВРУШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

КАРТА ГРАНИЦ ЗОН С ОСОБЫМИ УСЛОВИЯМИ ИСПОЛЬЗОВАНИЯ ТЕРРИТОРИЙ



Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының
«Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең

# ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

III өлеш

## ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕ РЕГЛАМЕНТЛАРЫ

2025

**Эчтәлек**

9 нчы бүлек. Территориаль зоналар һәм шәһәр төзелеше регламентлары турында гомуми белешмәләр

14 статья. Территориаль зоналар төрләре исемлеге

15 статья. Шәһәр төзелеше регламенты составы

10 нчы бүлек. ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕ РЕГЛАМЕНТЛАРЫ

16 статья. Территориаль зоналар төрләре буенча шәһәр төзелеше регламенты

17 статья. Чикләрендә территорияне комплекслы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру каралган территорияләргә карата шәһәр төзелеше регламенты

## 9 нчы бүлек. Территориаль зоналар һәм шәһәр төзелеше регламентлары турында гомуми белешмәләр

14 статья. Территориаль зоналар төрләре исемлеге

1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында кагыйдәләр составында түбәндәге төрдәге территориаль зоналар билгеләнә:

| т/с | Зона индексы | Атамасы | Тасвирлама |
|---|---|---|---|
| 1 | **Ж-У** | Универсаль торак зонасы | Социаль-көнкүреш һәм коммерция билгеләнешендәге объектларның киң исемлеге булган индивидуаль, блокланган торак төзелеше һәм аз катлы күпфатирлы торак төзелеше территорияләре. |
| 2 | **Р-У** | Универсаль ял итү зонасы | Хезмәт күрсәтү, ял итү һәм ял итү объектларының чикләнгән исемлеге урнаштырылган рекреацион максатларда төзекләндерү өчен билгеләнгән табигый һәм ясалма яшелләндерү өлеше югары булган территорияләр (парклар, скверлар, бульварлар, мәйданнар, яр буйлары һәм гомуми файдаланудагы башка яшелләндерелгән территорияләр); шифаханә-курорт эшчәнлеге, табигый-танып белү туризмы, туристлык хезмәт күрсәтү һәм спорт билгеләнешендәге объектларның территорияләре. |
| 3 | **П-1** | Әйләнә-тирә мохиткә сизелерлек йогынты ясый торган киң профильле җитештерү предприятиеләре зонасы | Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясау дәрәҗәсе югары булган (i-V классы хәвефлелек) җитештерү объектлары территорияләре, аларны торак төзелешеннән шактый ераклыкта урнаштыру тәкъдим ителә. |
| 4 | **С-1** | Җирләү урыннары зонасы | Гамәлдәге һәм күмү өчен ябык зиратлар, крематорийлар, колумбарийлар урнашкан территорияләр. |
| 5 | **СХ-2** | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар зонасы | Капиталь төзелеш объектларын урнаштырып, авыл хуҗалыгы файдалануы өчен билгеләнгән территорияләр. |

2. Территориаль зонаның һәр төре территориаль зона төре исеменә һәм зона индексына ия. Һәр территориаль зонаның уникаль номеры бар һәм ул территориаль зоналар чикләре турындагы белешмәләр реестрының аерым объекты булып тора. Территориаль зона төренә карап билгеләнгән шәһәр төзелеше регламенты, территориаль зонаның уникаль номерына бәйсез рәвештә, зонаның тиешле индексы булган барлык территориаль зоналарга да кагыла.

3. Территориаль зонаның уникаль номеры торак пункт чигенең һәм территориаль зонаның тәртип номерыннан тора. Территориаль зоналарга уникаль

номер бирү максатларында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составындагы торак пунктлар чикләренең түбәндәге нумерациясе кертелә:

| **Торак пункт чигенең тәртип номеры** | **Торак пунктының исеме** |
|---|---|
| 1 | Иске Саурыш авылы |
| 2 | Васильевка бистәсе |
| 3 | Түбән Саурыш авылы |
| 4 | Саурыш авылы |

Территориаль зона торак пунктлар чикләреннән читтә урнашкан очракта, территориаль зонаның уникаль номерының беренче билгесе «0» итеп кабул ителә

15 статья. Шәһәр төзелеше регламенты составы

1. Шәһәр төзелеше регламентында тиешле территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына карата түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге п/0412 номерлы боерыгы нигезендә җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре;

2) җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын төзүнең һәм реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрлары;

3) җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган чикләүләр;

4) аңа карата шәһәр төзелеше регламенты билгеләнә торган территориаль зона чикләрендә территорияне комплекслы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру күздә тотылган очракта, территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәпләмә күрсәткечләре һәм күрсәтелгән объектларның халык өчен территориядән

файдалана алуының мөмкин булган максималь дәрәҗәсенең исәпләмә күрсәткечләре.

2. Рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләренә яисә шартлы рөхсәт ителгән файдалану төрләренә карата өстәмә буларак кына рөхсәт ителә һәм алар белән бергә гамәлгә ашырыла. Рөхсәт ителгән файдалануның сайланган ярдәмче төре капиталь төзелеш объектларын урнаштыруны күздә тоткан очракта, аларны төзү рөхсәт ителгән файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төп төрләрен гамәлгә ашырудан алда булырга мөмкин (ләкин җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан фактта бердәнбер файдалану була алмый).

Әгәр шәһәр төзелешен проектлау нормативлары, техник регламентлар таләпләрендә, Россия Федерациясе законнарында каралган башка мәҗбүри таләпләрдә башкача билгеләнмәгән булса, җир кишәрлеге территориясендә ярдәмче файдалану төрләре капиталь төзелеш объектларының суммар гомуми мәйданы файдалануның төп һәм шартлы рөхсәт ителгән төрләре капиталь төзелеш объектларының суммар гомуми мәйданының 25 процентыннан артмаска тиеш.

Файдалануның төп һәм шартлы рөхсәт ителгән төрләре булган, мәйданчыклар, ачык корылмалар (базарлар, автомобиль кую урыннары, причаллар һәм капиталь төзелеш объектлары булмаган башка объектлар) рәвешендә тәкъдим ителгән һәм территориядә капиталь төзелеш объектларын урнаштыруны күздә тотмаган эшчәнлек төрләре (мәдәният һәм ял паркларын урнаштыру, табигатьне махсус саклау һәм өйрәнү эшчәнлеге, табигать территорияләрен саклау һ.б.) булган җир кишәрлекләре өчен җир кишәрлегенең ярдәмче файдалану төрләре өчен бирелә торган өлеше җир кишәрлегенең гомуми мәйданының 25 процентыннан артмаска тиеш.

3. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) җир кишәрлекләренең минималь һәм максималь мәйданын (кв.м);

2) җир кишәрлекләренең алгы чигенең минималь киңлеген (м).

4. Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрлары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) капиталь төзелеш объектларының җир кишәрлекләре чикләреннән (алгы чиктән һәм башкалардан) минималь чигенешләрне (м);

2) катларның максималь санын (кат);

3) биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның максималь биеклеген (м);

4) җир кишәрлеге чикләрендә төзелешнең максималь процентын (%);

5) капиталь төзелеш объектының максималь мәйданы (кв.м);

6) капиталь төзелеш объектының куркынычлык классы.

5. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны чикләүләр Төрләре Россия Федерациясе Җир кодексының 105 статьясында билгеләнгән һәм чикләре Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар турындагы нигезләмәләр нигезендә билгеләнә.

6. Аңа карата шәһәр төзелеше регламенты билгеләнә торган территориаль зона чикләрендә территорияне комплекслы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру күздә тотылган очракта, территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәпләмә күрсәткечләре һәм күрсәтелгән объектларның халык өчен территориядән файдалана алуының мөмкин булган максималь дәрәҗәсенең исәпләмә күрсәткечләре Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлауда җирле нормативлары нигезендә билгеләнә.

7. Билгеләнергә тиеш булмаган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре, рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрлары шәһәр төзелеше регламентында Кагыйдәләрнең территориаль зоналарына карата «б-мәгән» дип билгеләнә.

# 10 нчы бүлек. ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕ РЕГЛАМЕНТЛАРЫ

16 статья. Территориаль зоналар төрләре буенча шәһәр төзелеше регламенты

## 1. Универсаль торак зонасы (Ж-У)[1]

| Рөхсәтле файдалану төрләре | | Җир кишәрлекләренең (җ.к.) иң чик күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын төзүнең һәм реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрлары (ОКС) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Код | Атамасы | Җ.к. мәйданы (кв.м) | Җ.к. алгы чигенең киңлеге (м) | Җ.к. чикләрендә төзелеш проценты (%) | Катлар саны (кат) | Биналарның, төзелмәләр-нең, корыл-маларның биеклеге (м) | Җ.к. алгы/ башка чикләреннән ОКС чигенешләре (м) |
| | | мин./макс | мин. | Макс. | Макс. | Макс. | мин. |
| **ТӨП** | | | | | | | |
| 2.1 | Индивидуаль торак төзелеше өчен | 1000/2500 | 20 | 50 | 3 | 13 | 3/3 |
| 2.2 | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт яны җир кишәрлеге) | 1000/2500 | 20 | 40 | 3 | 13 | 3/3 |
| 2.3 | Блокланган торак төзелеше | 1000/2500 | б-мәгән | 60 | 3 | 13 | 3 алгы /0 ян-як (бер-берсенә тоташкан блоклар өчен); 3 - башка очракларда |
